БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 ноябрь 2018 ел № 153

**Балтач муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Балтач районы прокуратурасының 2018 нче елның 10 сентяберендәге 02-08-02-2018 номерлы Балтач район Советының 2005 елның 8 декабрендә кабул ителгән 22 номерлы карары буенча протесты һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. 2005 елның 22 декабрендәге 22 номерлы карары белән (2010 елның 13 ноябрендәге редакциядә) расланган Балтач муниципаль район Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә №1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2.Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин

01.11.2018 елгы № 153
Татарстан Республикасы
Балтач район Советы карарына
№1 кушымта

**Балтач муниципаль район Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр**

1. Нигезләмә атамасындагы “Балтач муниципаль район Советы” сүзтезмәне “Татарстан Республикасы Балтач район Советы” сүзтезмәсе белән алмаштырырга.

2. Нигезләмәнең статья 1 пункт 1, статья 3 пункт 3, статья 4 пунктлар 2, 3, 4, статья 5 пункт 2, статья 7 пункт 1 подпунктлар 1, 2, 5, 6, статья 8 пункт 3, статья 9 пунктлар 1, 2, пункт 3 подпунктлар 1-6,8, статья 10 пункт 1, статья 13.1, статья 14 пунктлар 1, 2, 3, статья 16 пункт 1 подпунктлар 1, 4, пункт 2, статья 18 пунктлар 1, 2, 3, статья 19 пункт 1, 2, 21 статьясындагы “Балтач муниципаль район Советы” сүзтезмәне “Татарстан Республикасы Балтач район Советы” сүзтезмәсе белән алмаштырырга.

3. Нигезләмәнең 3 статьясындагы 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «1. Депутат вәкаләтләре срогы кимендә ике һәм биш елдан артык була алмый».

4. Нигезләмәнең 9, 10, 18 статьялары исемендә “Балтач муниципаль район Советы” сүзтезмәне “Татарстан Республикасы Балтач район Советы” сүзтезмәсе белән алмаштырырга.

5. Нигезләмәнең 13.1 статьясында “район” сүзен төшереп калдырырга.

6. Нигезләмәнең 16 статьясындагы 1 пунктының 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5) хезмәт вазифаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгын китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килгәндә - бу турыда Татарстан Республикасы Балтач район Советына хәбәр итәргә һәм әлеге мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калуга яки җайга салуга юнәлтелгән карарларны үтәргә.».

7. Нигезләмәнең 17 статьясындагы 2 пункты төшереп калдырырга.